**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы**
**Түбән Суык-Су авыл җирлеге**
**Югары Суык-Су авылында**

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

« 12 » ноябрь 2024 ел

№ 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Югары Суык-Су авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2025 елда яшәү урыны буенча Түбән Суык-Су авыл җирлеге Югары Суык-Су авылында территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә һәм РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взнослар түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны ремонтлау, вак таш, асфальт валчыгы сатып алу, китерү, махсус техника хезмәте күрсәтү);
- Һәйкәлләр (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган) төзү, ремонтлау һәм янәшә территорияне төзекләндерү (бөек Ватан сугышы һәйкәлен төзекләндерү (сугышчыны буяу, яңарту));
- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү (чишмә территориясен төзекләндерү);
- су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, торбаларны алыштыру, ремонт эшләре).

2. Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Югары Суык-Су авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Югары Суык-Су авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башлыгы — Р.Г.Нуруллин